**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» января 2025 №15

**Әтнә районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында" 08.02.2018 елның 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.08.2017 ел, № 569 карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасынның 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә район башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 08.02.2018 елның 29 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең II өлешендәге 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче Таблица

| п/п | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Зурлык вазыйфаи оклады, |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | сум |
| | 2 | 3 |
| | Учреждение Җитәкчесе | 27560 |
| | Учреждениенын оператив дежурные | 21200 |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (https://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов